РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» апреля 2024 ел г. Альметьевск № 1561

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт шәһәре территориясендә велосипедларны, роликларны, самокатларны һәм башка спорт инвентарен прокатка бирү пунктлары исемлеген һәм схемасын раслау турында» 2022 елның 23 маендагы 974 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә җир кишәрлекләре бирелмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру мөмкин булган объектлар төрләре исемлеген раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 3 декабрендәге 1300 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт шәһәре территориясендә велосипедларны, роликларны, самокатларны һәм башка спорт инвентарен прокатка бирү пунктлары исемлеген һәм схемасын раслау турында» 2022 елның 23 маендагы 974 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 17 апрелендәге 968 номерлы, 2023 елның 15 маендагы 1371 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт шәһәре территориясендә велосипедларны, индивидуаль мобиль чараларын, төрле спорт инвентарын туктату һәм (яки) саклау өчен билгеләнгән вакытлыча корылмаларны һәм (яки) вакытлыча конструкцияләрне урнаштыру урыннары һәм схемалары исемлеген раслау турында»;

карарның 1 пунктында һәм алга таба карарның барлык тексты һәм кушымталары буенча «велосипедлар, роликлар, самокатолар һәм башка спорт инвентарен прокатлау пунктлары» сүзләрен «велосипедларны, индивидуаль мобиль чараларын, төрле спорт инвентарын туктату һәм (яки) саклау өчен билгеләнгән вакытлыча корылмалар һәм (яки) вакытлыча конструкцияләр» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып

заказ № 1-851

чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары И. И. Сәлимгәрәевка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов